КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 11 март г.Казань № 201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмәк шартнамәләрне теркәп хәбәр итү тәртибе турында» 2007 ел, 27 июнь, 258 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмәк шартнамәләрне теркәп хәбәр итү тәртибе турында» 2007 ел, 27 июнь, 258 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 июнь, 465 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «дәүләт учреждениеләре – Татарстан Республикасының тиешле шәһәрендәге, районындагы халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре» сүзләрен «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында күмәк шартнамәләрне теркәп хәбәр итү тәртибендә:

1.3 пунктның беренче абзацында «дәүләт учреждениеләре – Татарстан Республикасының тиешле шәһәрләрендәге, районнарындагы халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре» сүзләрен «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктның сигезенче абзацында «план» сүзен төшереп калдырырга;

2.2 пунктның икенче абзацында «һәм әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында китерелгән, билгеләнгән форма буенча аңа теркәү картасын тутыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин